КАРАР

2022 елның 25 ноябре № 2

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге Югары-Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

:

- Югары-Чура авылының Тынычлык, Яшьләр-Яр буе тыкрыгы урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылы Яр буе, Яшьләр, Комсомол урамнарында. вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылының Мәктәп, Вахитов урамнарына юл билгеләре сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылының Вахитов, Мәктәп, Комсомол урамында автомобиль юлын (переход) ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Югары-Чура авылындагы балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Югары-Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Югары-Чура авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Югары-Чура авылының Вахитов урамында асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 475 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 258.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 258 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары-Чура авыл җирлеге ЮгарыЧура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокллы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар иттек:

:

- Югары Чура авылы Тынычлык урамында, Яшьләр – Яр буе, Яр буе – Пионер урамнары тыкрыгы юлларына вак таш җәю һәм юлларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары-Чура авылы Яр буе, Яшьләр, Комсомол, Пионер, Вахитов урамнарында, вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;
- Югары Чура авылының Мәктәп, Вахитов урамнарына юл билгеләре һәм ясалма тигезсезлекләр сатып алу һәм урнаштыру;
- насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су башняларын, су саклау зоналарын карап тоту, Югары-Чура авылын су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;
- Югары-Чура авылының Вахитов, Мәктәп, Комсомол урамында автомобиль юлын (переход) ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары-Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы-машинист хезмәте күрсәтү;
- Югары-Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;
- Югары-Чура авылына видеокамералар һәм видеокүзәтү системалары сатып алу һәм урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Югары-Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары-Чура авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;
- Югары-Чура авылында юлларга асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары-Чура авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Андреев